Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 20 ноябре

2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 20 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге составына керүче Иске Чаллы авылындагы гражданнар җыенын узган, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толлары, 5 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

– авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кардан чистарту, чүплекләрне күмү) белән бәйле чыгымнарга - 220 сум;

- суэтем башняларын лицензияләү һәм эчәргә яраклы су анализын алу, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башняларын коймалау һәм буяу белән бәйле чыгымнарга-120 сум;

- урам утларын урнаштыруга материал (яктырткычлар) сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, урам яктыртуы энергиясе өчен түләүгә – 115 сум;

- балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнарга-80 сум;

- контейнерлар сатып алу һәм чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнар һәм килешү буенча белгечләргә түләүгә– 65 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның толлары, 5 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

– авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кардан чистарту, чүплекләрне күмү) белән бәйле чыгымнарга - 220 сум;

- суэтем башняларын лицензияләү һәм эчәргә яраклы су анализын алу, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башняларын коймалау һәм буяу белән бәйле чыгымнарга-120 сум;

- урам утларын урнаштыруга материал (яктырткычлар) сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, урам яктыртуы энергиясе өчен түләүгә – 115 сум;

- балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнарга-80 сум;

- чүп-чар өчен контейнерлар сатып алу һәм контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнар һәм килешү буенча белгечләргә түләүгә – 65 сум;

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Чаллы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы: М. Г. Исхаков